Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

25 март 2019 ел №280

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2012 елның 19 октябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының Рәхмәте турында» №228 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2012 елның 19 октябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының Рәхмәте турында» № 228 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының Рәхмәте турындагы Нигезләмәне һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының Рәхмәте бланк формасын № 1 һәм № 2 кушымталар нигезендә расларга (теркәлә).

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә. Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И. Р.).

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советының
2019 елның 25 мартындагы №280
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының
Рәхмәте турында Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының Рәхмәте (алга таба – Рәхмәте) Әлмәт муниципаль районы гражданнары тормышын яхшыртуга юнәлдерелгән җирле үзидарә, икътисад, сәнәгать, авыл хуҗалыгы, фән, мәдәният, сәнгать, мәгариф, сәламәтлек саклау, спорт үсешенә зур өлеш керткән өчен, законлылыкны, хокук тәртибен тәэмин итүдәге хезмәте, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклаудагы казанышлары, хуҗалык, фәнни, социаль-мәдәни, иҗтимагый, хәйрия эшчәнлегендәге югары казанышлары өчен гражданнарга һәм предприятие, учреждение, оешма коллективларына, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы каршындагы башка казанышлары өчен рәхмәт белдерү формасы булып тора.

2. Бүләкләү тәртибе

1. Рәхмәт белән бүләкләү муниципаль район Башлыгы боерыгы белән башкарыла.

2. Бүләкләү турындагы үтенеч хаты белән милек формасына бәйсез рәвештә, муниципаль район территориясендә эшчәнлек башкаручы предприятие һәм оешмаларның хезмәт коллективлары, иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Рәхмәт белән бүләкләү турындагы мәсьәләне муниципаль район башлыгы шәхсән үзе башлап җибәрергә хокуклы.

3. Үтенеч хатында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелергә тиеш:

- гражданнарны бүләкләү өчен: кыскача биографик мәгълүматлар һәм төгәл хезмәтләр күрсәтелгән характеристикалар;

- коллективларны бүләкләү өчен: оешманың, предприятиенең, учреждениенең тулы исеме һәм кыскача белешмә, аның коллективының төгәл хезмәтләре.

4. Рәхмәтне әзерләү үтенеч хаты кергән көннән алып 30 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

5. Республика, шәһәр масштабындагы уңышлы әзерләнгән һәм уздырылган чаралар һәм акцияләрдән тыш, алдагы бүләкләү тантанасыннан соң ике елдан да иртәрәк яңа хезмәтләр өчен кабат бүләкләү мөмкин түгел.

6. Рәхмәтне югалтканда дубликат бирелми.

### 3. Район Башлыгының Рәхмәте тасвирламасы

Рәхмәт А3 форматындагы тыгыз кәгазь битеннән гыйбарәт, 60 мм киңлектәге фоторәсем өчен рамка белән пыяла астына урнаштырылган, тулы төсле басма ысул белән эшләнгән.

60 мм калдырып өске сул як почмагында кызыл төстәге орнамент, түбән уң як почмагында яшел төстәге орнамент урнашкан.

Рәхмәт тексты саклагыч тангиралы челтәр фонында урнашкан.

Өстәге кырыйдан 80 мм ераклыкта уртада Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы гербы сурәтләнгән (алга таба - район гербы).

Гербтан 3 мм аста 4 мм биеклектәге хәрефләр белән бер юлга «ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ» дигән сүзләр урнашкан.

10 мм аста 10 мм биеклектәге хәрефләр белән, 30 мм биеклектәге баш хәреф белән «Рәхмәт» сүзе урнаштырылган.

Түбәнрәк бит уртасында бүләкләнүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, вазифасы, яисә юридик затның исеме, хезмәтләренең кыскача тасвирламасы күрсәтелә.

15 ммда түбәнрәк, Әлмәт муниципаль районы башлыгының имзасы инициаллары һәм фамилиясе языла.

Түбәндә уртада - «Әлмәт шәһәре» реквизиты.

### 4. Башлык Рәхмәтен тапшыру

Башлык Рәхмәтен тапшыру тантаналы шартларда Әлмәт муниципаль районы Башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Әлмәт муниципаль районы Башлыгы кушуы буенча һәм аның исеменнән аның урынбасарлары, район Советы аппараты җитәкчесе, район (шәһәр) башкарма комитеты җитәкчесе, аның урынбасарлары тапшыра ала.

### 5. Башлык Рәхмәтен рәсмиләштерү, исәпкә алу һәм теркәү

Әлмәт муниципаль районы Башлыгының Рәхмәтен рәсмиләштерү, исәпкә алу һәм теркәү Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының кадрлар һәм бүләкләр бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль район Советының
2019 елның 25 мартындагы №280
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының Рәхмәте бланкы формасы




Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин